**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сәпәй авыл жирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сәпәй авылы №115 «06» март 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге 13 июнендәге 2012 елның 42 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (07.11.2013 №69, 25.02.2014 №81, 16.02.2015 №116, 03.04.2015 №123, 04.03.2016 №25, 23.04.2019 №127, 01.06.2021 №28 карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны җирле үзидарә турындагы федераль һәм республика кануннарына туры китерү максатында

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге 13 июнендәге 2012 елның 42 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (07.11.2013 №69, 25.02.2014 №81, 16.02.2015 №116, 03.04.2015 №123, 04.03.2016 №25, 23.04.2019 №127, 01.06.2021 №28карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктта:

а) 13 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 21 абзац өстәргә:

«ирекле корылманы җимерү, рөхсәтсез корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнец иң чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итү, капиталь төзелеш объектларын җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән туры китерү.»

1.2. 4 нче Бүлектә:

а) 4.5 пунктның 6 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»

б) 4.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 абзац өстәргә:

- «ирекле корылманы җимерү турында, рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү хакында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр нигезендә карар кабул итә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http//aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сәпәй авыл җирлегенең законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Ф.Г.Галиева